КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 август

г.Казань

№ 977

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе мәсьәләләре» 2005 ел, 5 август, 391 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 431 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 649 нчы; 2006 ел, 1 март, 90 нчы; 2006 ел, 14 август, 415 нче; 2008 ел, 5 март, 137 нче; 2008 ел, 5 май, 289 нчы; 2009 ел, 10 июнь, 383 нче; 2010 ел, 19 июль, 574 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 ноябрь, 921 нче; 2011 ел, 25 ноябрь, 965 нче; 2012 ел, 31 август, 742 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 21 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 824 нче; 2014 ел, 26 февраль, 123 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 730 нчы; 2016 ел, 26 август, 593 нче; 2018 ел, 8 август, 644 нче; 2018 ел, 31 октябрь, 976 нчы; 2018 ел, 18 декабрь, 1159 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1299 нчы; 2020 ел, 17 февраль, 120 нче; 2020 ел, 24 август, 724 нче; 2020 ел, 3 ноябрь, 987 нче; 2021 ел, 17 март, 139 нчы; 2021 ел, 13 август, 720 нче; 2021 ел, 21 декабрь, 1260 нчы; 2022 ел, 26 октябрь, 1142 нче; 2023 ел, 14 гыйнвар, 9 нчы; 2023 ел, 20 март, 288 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше дәүләт тарафыннан җайга салыну турында һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча» 2005 елның 25 июлендәге ПУ-299 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте системасы һәм органнары турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

4 – 6 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта «, предприятиеләр һәм учреждениеләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3 пунктның егерме икенче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның уникенче абзацында «башкарма хакимият органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның беренче абзацында «предприятиеләр һәм оешмаларның» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.2 пунктның тугызынчы абзацында «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «, учреждениеләр, предприятиеләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин